# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлегенең Чүрчиле торак пунктында**

**22 нче ноябрь 2023 нче ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлегенең Чүрчиле торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлегенең Чүрчиле торак пунктында яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500,00 сум күләмендә гражданнарның үзара салым салу чаралары кертергә, Бөек Ватан сугышында катнашучы һәм инвалидлардан, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

   1. торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын ремонтлау һәм тоту, инерт материаллар сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру;
   2. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру;
   3. янгынга каршы коены урнаштыру һәм монтажлау , ремонтлау, янгын гидранты урнаштыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, шулай ук Олы Карауҗа авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында: Татарстан Республикасы адреслары буенча: Олы Карауҗа авылы, Мирная урамы, 41 йорт (советның административ бинасы), Олы Карауҗа, Күпер урамы, 23 йорт (СДК бинасы).

**Рәислек итүче**
**гражданнар җыенында** **Р.Ф. Хөснетдинов**

**Олы Каруҗа**
**авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **Р. Ф. Хөснетдинов**